КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 6 октябрь г.Казань № 806

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 17 май, 327 нче карары белән расланган «Китапханәләрдән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Китапханәләрдән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында» 2013 ел, 17 май, 327 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 май, 300 нче, 2015 ел, 15 сентябрь, 679 нчы, 2016 ел, 6 сентябрь, 615 нче, 2016 ел, 19 декабрь, 951 нче, 2018 ел, 4 декабрь, 1082 нче, 2018 ел, 13 декабрь, 1128 нче, 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче, 2020 ел, 10 апрель, 270 нче, 2023 ел, 16 июнь, 723 нче, 2023 ел, 24 октябрь, 1349 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Китапханәләрдән файдаланучыларга китапханә, библиография һәм мәгълүмат хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыру» дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлектә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге норматив хокукый актлар, методик, инструктив һәм гамәлгә кую документлары белән регламентлана:»;

уникенче абзац үз көчен югалткан дип таныргга;

түбәндәге эчтәлекле 2.2 пункт өстәргә:

«2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнми.»;

9.1 пунктның беренче абзацында «кулланучылар белешмәләре» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучылар белешмәләре» сүзләренә алмаштырырга;

12.1 пунктта «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы» сүзләрен «китапханәне гамәлгә куючының функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы республика башкарма хакимияте органы (алга таба – Гамәлгә куючы)» сүзләренә алмаштырырга;

12.2 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

12.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.4. Шикаять китапханәгә, Гамәлгә куючыга кергәннән соң өч эш көне эчендә теркәлергә тиеш, һәм аның теркәлгән көненнән алып 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, әгәр дә китапханәнең, Гамәлгә куючының дәүләт хезмәте алучыдан документлар кабул итүдән баш тартуга яки җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүгә яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга шикаять бирелгән очракта – теркәлгән көненнән алып биш эш көне эчендә каралырга тиеш.»;

12.5 пунктта «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» сүзләрен төшереп калдырырга, «гариза бирүче» сүзләрен тиешле килешләрдә «дәүләт хезмәте алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.6 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәте алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.7 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.9 пунктта «Мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «Дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

14.1 пунктта «һәм түләүле нигездә» сүзләрен төшереп калдырырга;

14.2 һәм 14.3 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин